Республика Татарстан

**СОВЕТ КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Советская, д. 66в, д.Кавзияково
423377
Телефон: 4-47-16

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘУЖИЯК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Кәүҗияк авылы, Совет урамы, 66в йорты,
423377
Телефон: 4-47-16

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« 25 » ноябрь 2022 ел № 17

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының « 2023 елга һәм 2024, 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге бюджеты турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Кәүҗияк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 елларның план чорына бюджеты турында» карары проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшне дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлегенең 2023 елга һәм 2024, 2025 елларның план чорына бюджеты турында» карары проектына кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:
- Хөснетдинов Фиргать Әхсән улы- төркем җитәкчесе;
- Фатыйхов Шамил Миннешәех улы- төркем әгъзасы;
- Зиатдинова Раушания Әсгат кызы- төркем әгъзасы;
- Сәлахова Гөлшат Галалетдин кызы- төркем әгъзасы;

4. Карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәре эшче төркемгә Ф.И.О, авторның туган елын, адресын күрсәтеп, түбәндәге адрес буенча җибәрелә: ТР, Кәүҗияк авылы, Совет урамы, 66в.

5. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының 2023 елга һәм 2024, 2025 елларның план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны 2022 елның 9 декабрендә 15.00 сәгатьтә авыл җирлеге Советының утырышлар залында билгеләргә.

6. Эшче төркемгә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы депутатларының төзәтмәләрен һәм карар проектына карата гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә, карар проектын эшләп бетерергә һәм аны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советына карап тикшерүгә 2022 елның 12 декабренә кадәр кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кәүҗияк авыл җирлеге
Советы рәисе Ф.А.Хөснетдинов